СОВЕТ ПОДЛЕСНО-ШЕНТАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ УРМАН АСТЫ ШОНТАЛАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с. Подлесная Шентала **КАРАР**

10.04.2023 № 33

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге Советының 05.08.2020 ел №124, депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге җирле үзидарәсенең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып бирү артык зур булмаса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе турында карары белән расланган Тәртипкә үзгәрешләр кертү турында**

2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында»Татарстан Республикасы законына, 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына, Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге Советының 15.08.2022 № 23 карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә

**Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге Советының 05.08.2020 ел №124, депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге җирле үзидарәсенең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган

балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып бирү артык зур булмаса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе турында карары белән расланган Тәртипкә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)» (алга таба – Татарстан Республикасы Рәисе) сүзләре белән алыштырырга»;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

5 пунктның 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

6 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

1 нче абзацта; 7 нче пунктның 3 нче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

11 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **А.Ә.Җиһаншин**